Хәерле көн хөрмәтле Айдар Фаслахович!

Хормэтле жирлегебез депутатлары, мөхтәрәм кунаклар, авылдашлар!

Бүген сезнең карамакка узган 2015 елда авылларыбызның социаль-экономик үсеше турында отчет тәкъдим итәм.

“Бикбау авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы һәм башкарма комитеты Положениесе нигезендә авыл җирлеге Советы һәм башкарма комитеты бюджет үтәлеше, территорияләрне төзекләндерү, яшелләндерү буенча мероприятияләр оештыру, урамнарны яктырту, пожар куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү, авылларыбызны газ, электр, су белән тәэмин итү эшләре белән шөгыльләнә. Бу эшләр авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә норматив документлар әзерләү, халык белән очрашулар һәм җыеннар оештыру, авыл җирлеге башлыгы һәм урынбасары тарафыннан халыкны шәхси кабул итү, телдән һәм язмача кергән гаризаларны караудан гыйбарәт.

2015 елда төрле сораулар белән барлыгы 58 кеше мөрәҗәгать иткән, 1 язмача гариза кергән, барлыгы 424 белешмә бирелгән. Ел дәвамында авыл җирлеге башлыгы тарафыннан 6 распоряжение чыгарылган. Барлык сораулар да каралган, кубесе уңай хәл ителгән. Гражданнардан кергән сорауларны хәл итү буенча даими рәвештә эш алып барыла. Халык күбрәк җир участоклары сорап, җир һәм торакларны рэсмилэштеру, урамнарны яктырту, көнкүреш мәсьәләләрендә үзләрен борчыган сораулар белән мөрәҗәгать итте.

Хәзерге көндә Бикбау авыл җирлеге Советы 7 депутат составында эшен план нигезендә алып бара.

1округ- Сарваров Марсил Мирзафатихович
2 округ – Закиров Илгиз Фатихович
3 округ – Ахметханов Илгизар Назифович
4 округ - Гильметдинов Фиркат Закиевич
5 округ – Усманова Энже Фависовна
6 округ – Набиева Салиса Раффаковна
7 округ- Мардамшина Люзия Назиповна.
Шулай ук авылнын ветераннар советы белән дэ эш тыгыз элемтэдэ урнаштырылган.

Авыл җирлеге Советының 2015 елда планлаштырылган 13 утырышында барлыгы 27 сорау каралды, халыкның тормыш шартларын яхшырту, авыл җирлеге территориясендә куркынычсызлык һәм тәртип булдыру, халык өчен кирәк булган барлык социаль объектларның һәм учреждениеләрнең өзлексез эшләвен тәэмин итү, авылларны төзекләндерү максатыннан 27 карар кабул ителде һәм аларны тормышка ашыру өчен бик куп эшләр башкарылды

Бикбау жирле үзидарәсе территориясендә 3 авыл урнашкан: Бикбау, Куян, Ахматовка.

Территория 3989 га җирне биләп тора. Шуларның 2860 га ры чәчүлек басу , 179 га ры көтүлек һәм 183га ры болынлыклар.

2015 ел күрсәткечләренә тукталып китик:
Бикбау авыл җирлегендәге хуҗалыклар һәм халык
саны буенча 2016 елның 1 январена мәгълүмат

| №п/ п | Күрсәткечләр исемлеге | 01.01. 2014 | 01.01. 2015 | 01.01. 2016 | Үзгәреш |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **Торак саны** | | | | |
| | Бикбау | 404 | 406 | 408 | +2 |
| | Куян | 50 | 50 | 50 | - |
| | Ахматовка | 16 | 16 | 16 | - |
| | **Барлык торак** | 470 | 472 | 474 | +2 |

Бу урында шундый мәгълүматка тукталып утэсе килэ.
Мэгълүмат 2016 елның 1 январена алынды

| | | Барлык йортлар саны | Бугенге кондэ яшилэр | Дачник лар | Яшэмилэр |
|---|---|---|---|---|---|
| | Бикбау | 408 | 193 | 124 | 91 |
| | Куян | 50 | 17 | 5 | 28 |
| | Ахматовка | 16 | 7 | 4 | 5 |
| | Барлыгы | 474 | 217 | 133 | 124 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **2** | **Халык саны** | | | | |
| | Бикбау | 520 | 506 | 486 | -20 |
| | Куян | 36 | 36 | 35 | -1 |
| | Ахматовка | 32 | 30 | 30 | - |
| | **Барлык халык** | **588** | **572** | **551** | **-21** |

Халык саны буенча да шундый ук мисал китерергэ була.

| | | Пропискада | Чынбарлыкта | Үзгэреш |
|---|---|---|---|---|
| | Бикбау | 486 | 297 | -189 |
| | Куян | 35 | 27 | -8 |
| | Ахматовка | 30 | 15 | -15 |
| | **Барлыгы** | **551** | **339** | **-212** |

Таблицадан куренгэнчэ, 212 кеше пропискада Бикбауда булып та авылда яшэмилэр.
Калган мэгълүматлар барысы да бугенге кондэ авылда яшэучелэрдэн генэ чыгып тозелде.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **3** | **Эшкэ яраклы халык** | **70** | **66** | **63** | **-3** |
| 4 | **Эшлэучелэр** | **37** | **36** | **33** | |
| | Бикбау | 31 | 30 | 27 | -3 |
| | Куян | 2 | 2 | 2 | - |
| | Ахматовка | 4 | 4 | 4 | - |
| **5** | **Эшсезлэр** | **35** | **30** | **30** | -1 |
| | Бикбау | 33 | 27 | 27 | - |
| | Куян | 2 | 3 | 3 | - |
| | Ахматовка | - | - | - | - |
| 6 | **Пенсионерлар** | **295** | **286** | **276** | **-10** |
| | Бикбау | 264 | 255 | 246 | -9 |
| | Куян | 19 | 19 | 18 | -1 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ахматовка | 12 | 12 | 12 | - |
| **8** | **Туучылар** | | | | |
| | Бикбау | 1 | - | 1 | - |
| | Куян | - | - | - | - |
| | Ахматовка | - | - | - | - |
| **9** | **Улучелэр** | **19** | **19** | **16** | **-3** |
| | Бикбау | 17 | 18 | 15 | -3 |
| | Куян | 2 | - | 1 | -1 |
| | Ахматовка | - | 1 | - | - |

Авылның 77 % пенсионерлар (уртача яше-67,1) булса да авыл әле яши. Авыл халкынын тормышы, күп финанс чыгымнары чыгуга карамастан, көннән-көн яңара, матурая, яшелләндерелә, торак йортлар, сарай-гаражлар, теплицалар төзелә хәм капка-коймалар заманча төзелеш материаллары белән алыштырыла.

2015 елда 2 яна торак йорт (Бэхтиева Сания апа, Хаертдинов Флюн) тозелде.

Халык үз көнен үзе күрә, мал асрый, кош-корт үстерә, йорт яны участокларына бәрәңге, чөгендер утырта, печән чәчә.

2016 елнын 1 январена шәхси хуҗалыкларда асраган маллар

| №п/п | Исемлеге | 01.01.2014 | 01.01.2015 | 01.01.2016 | Үзгәреш |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | **Могезле эре терлек** | | | | |
| | Бикбау | 300 | 275 | 252 | -23 |
| | Куян | 20 | 23 | 20 | -3 |
| | Ахматовка | 10 | 9 | 8 | -1 |
| | **Барлыгы:** | **375** | **307** | **280** | **-27** |
| 2 | **Савым сыерлар** | | | | |
| | Бикбау | 140 | 121 | 103 | -2 |
| | Куян | 15 | 13 | 13 | |
| | Ахматовка | 9 | 4 | 3 | |
| | **Барлыгы** | **164** | **138** | **119** | **-19** |
| | **Сарыклар** | | | | |
| | Бикбау | 365 | 353 | 392 | |
| | Куян | 47 | 54 | 45 | |
| | Ахматовка | 16 | 13 | 10 | |
| | **Барлыгы** | **428** | **420** | **447** | **+27** |
| | **Атлар** | | | | |
| | Бикбау | 24 | 26 | 23 | |
| | Куян | 1 | 1 | 1 | |
| | Ахматовка | - | - | - | |
| | **Барлыгы** | **25** | **27** | **24** | **-3** |

Кургэнегезчэ, барлык курсэткечлэр буенча да безнен жирлектэ бары тик минус тамгасы гына тора. Монын сэбэбе итеп авылнын картаюын китерер идем.

Тубэндэге таблица безгэ аны ачыкларга ярдэм итэр дип уйлыйм. Авылда ин яшь гаилэ уртача 40 Гайнетдинов Илдар , ин карт гаилэ 89 Галимов Касим яшьтэ.

74-75 яшьлэрендэ дэ сыер асрый алган Фэрхетдинов Хэниф, Латипов Рэсим, Мухаметзянов Сэлимжан, Садретдинов Наил, Афлятунов Хэмит, Миргалимов Модэусэр, Нуриев Зофэр, 79 яшьлек Габдракипов Мостафа абый 2 сыер, 1 ат, 81 яшьлек Фархетдинова Тэскирэ апан сыер , 83 яшендэ дэ ат, сыер тота алган Асадуллин Мохтэр абыйларга сокланмый момкин тугел.

| **Сыер асраучылар** | **парлылар** | | | | **ялгызлар** | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яшь аралыгы | 40-50 | 50-60 | 60-70 | 70-85 | 45-50 | 50-60 | 60-70 | 70-80 |
| Бикбау | 6(10) | 18(39) | 18(23) | 10(11) | 3(3) | 7(7) | 8(8) | 2(2) |
| Куян | 2(4) | 1(2) | - | 1(2) | - | 1(2) | 1(1) | 1(2) |
| Ахматовка | 1(1) | - | - | 1(2) | - | - | - | - |
| **Барлыгы** | **9(15)** | **19(41)** | **18(23)** | **12(15)** | **3(3)** | **8(9)** | **9(9)** | **3(4)** |

Сыерлар кысыр калды, угезе булган хужалыкны 1 кон коту чиратыннан азат итеп, угезен чыгаруны сорарга кирэк булыр.

Үзләренең шәхси хуҗалыкларында Сафин Роберт 8 баш мал (4 савым сыеры, 4 иярчен, 20 баш сарык, 2 ат), Мәрдәмшин Фәсләх 8 баш мал (4 савым сыеры, 4 иярчен, 18 баш сарык), Гайнетдинов Нурлыбаян 3 баш мал (2 савым сыеры, 1 иярчен, 1 ат), Фазылов Рәүф 5 баш мал (4 савым сыеры, 1 иярчен) , Зәйнуллин Хәмәтнәби 5 баш мал (3 савым сыеры, 2 бозау), Миннегалиев Рәшит 7 баш мал (4 савым сыеры, 3 бозау) асрыйлар. Исемнәре аталган мал хуҗаларының яше барысының да 50 дән югары.

Җәйлектә малларны Бикбауда 2 урында чират буенча көтү оештырылды. Шуна да карамастан, югары очта яшэуче берничэ кеше иярченнэрен котугэ чыгармыйча, атауда йорттелэр. Мал ул саклап тормасан, хэзер басуга менеп китэргэ жай гына эзли. Мал хужалары берничэ кат кисэтелделэр. Алдагы елда мондый хэл кабатланмас дип уйлыйм.

Куян һәм Ахматовка авылларында мал саны киму сэбэпле малларны арканлап куя башладылар. Шулай да Мусин Ханиф абый белэн Кашапова Жэннэт апаларнын сыерлары бэйгэ куелмыйча, авыл халкынын бакчаларына кереп йорделэр.

Бу урында минем тагын урта очнын, көл урамынын берничэ кешесенэ мөрәҗәгать итэсем килә. Шәхси хуҗалыкларда асралган сарыкларыгызны көтүгә чыгаруны, күп кисәтүләргә дә карамастан, оештырып бетерә алмадыгыз. Сезнең кебек ук югары оч халкы сарыкларын чират буенча көтуне оештырды. Беркем дә иясез сарыгын авыл урамында, басуда йөртергә тиеш түгел. Авыл советы янындагы бакча, мәктәп, культура йорты яннары сарык көтүе туплый торган урын тугел. Басуда кемнәрнеңдер малы таптасын өчен иген дә чәчмиләр, печән дә үстермиләр.

Авыл халкы җәй көне болыннан үзенә җитәрлек печәнне үз көче белән чабып өеп куйды. Җәмилов Ралиф, Миннегалиев Рәшит, Хәертдинов Флүр, Кәримов Ришат, Асадуллин Фәндүс, Закиров Илгиз үз транспортлары белән халыкның печәнен чабу, рулонга кысу, алып кайтуда шәхси хуҗалыкларга ярдәм иттеләр.

Жирлек буенча барлыгы 1200т печэн эзерлэнде. Мал асрау өчен һәр хуҗалык үзенә җитәрлек күләмдә фураж сатып алды. Элекке елларны халык чапкан печәнен арьякта кибәнгә өеп калдыра да, кыш көне трактор белән сөйрәп алып кайта иде. Табигать шартлары хәзер үзгәреп тора. Кышкы боз трактор белән печәнне күтәрерлек дәрәҗәдә катмый. Шуна күрә печәнне, мөмкинлек табып, җәй коне ук ташып бетерергә кирәк. Бүгенге көндә болында калган печәнне атлар белән ташыйлар.

Халыкка үзеннән арткан продукцияне сату мөмкинлеге дә тудырылган. 2015 ел дәвамында үзеннән арткан 25 тонна ит продукциясен саткан. Бүген сөт җыю буенча бернинди проблема да юк. Шәхси сектордан сөт җыючы Тәнзилә апа һәм Хәсән абый Муллагалиевләр һәр көн килеп сөтләрне җыеп китәләр, акчасын да айныкын айга вакытында түләп баралар.

Таш җэелгэч, Зеленая, Садовая урамнарына да кереп, халыкнын сотен капка топлэреннэн ук алып китэлэр. Аларга эшлэрендэ хэвеф-хэтрсез юллар, сэламэтлек, гаилэлэренэ иминлек телэп, авыл халкы исеменнэн рэхмэт эйтэсе килэ.

2015 елда Бикбау һәм Куян авылларыннан 1736 центнер сөт җыелды. Ноябрь ае өчен 1 литр сөтнең бәясе 16 сумнан белән расчет ясалды.

Авыл җирлегендә 1 мәдәният йорты, 1 клуб, 2 китапханә, 2 ФАП, почта бүлекчәсе, 3 кибет 1 кунакханэ бар. "Р.Х.Каһиров исемендәге Аю төп гомуми белем бирү " мәктәбенә 6 бала йөреп укый. Автобус шоферы Илгиз Закиров өч авылдан балаларны җыеп, нинди генә һава торышы булуына карамастан, мәктәпкә йөртә.

Бикбаудагы мәдәният йорты һәм Куян клубы да бүгенге көндә яхшы гына эшләп киләләр, бәйрәмнәрдә төрле чаралар, яшьләр арасында бәйгеләр үткәрәләр. Мәдәният йорты капиталь ремонт ясауга мохтаҗ булып кала бирә.

Җирлектә 2 фельдшер–акушерлык пункты бар. Бикбауда урнашкан пунктка капиталь ремонт ясалды, ягьни канализация үткәрелде, электр үткәргечләре алыштырылды. Ләкин бүгенге көндә пунктта бик салкын. Бина гомуми җылыткычтан җылытылса да, пунктта торбалар бик нәзек булу сәбәпле, бүлмәгә җылы җитми. Җитәкчеләре Галиева Гөлфинә һәм Гилмуллина Вәзирә, Хамаева Вәсимә стажлы, үз эшләрен яхшы белүче медработниклар, үзләренең профессиональ медицина хезмәтләренә төгәл һәм җаваплы карыйлар. Бүгенге көндә халыкка вакытында беренче медицина ярдэме курсэтелэ.

2 китапханәдә дә шулай ук эш бара, Нуруллина Әлфия һәм Нигматуллина Җәмилә китап укучылар белән төрле чаралар уздыралар. Бикбау авылы китапханэчесе Нуруллина Элфиягэ аеруча рэхмэт эйтэсе килэ. Ул барлык эшлэрдэ дэ актив, район һәм Яр Чаллы шәһәрләренә үткәрелгән ярминкәләрдә дә ин куп эзерлэнеп катнашучы.

Бикбау почта бүлекчәсендә 1 җитәкче Гилметдинова Факыя, 2 хат ташучы Газетдинова Вәсимә, Асадуллина Гөлфинә эшли. Авыл халкы аларның эшеннән канәгать. Бүлекчәдә электр, газ, телефон хезмәтләренә түләү белән бергә һәртөрле кредитларны, штрафларны түләү мөмкинлеге дә бар. Шулай ук Ак барс терминалы эшли. Пластик карталары булган кешеләр элеге терминалдан файдалана алалар.

Бикбау авылында 2, Куян авылында 1 социаль яклау үзәге хезмәткәре 9 өлкән кешегә хезмәт күрсәтә. Эшләрен күңел биреп, тырышып башкаралар. Олкэн кеше ул бер жылы сузгэ, ягымлы карашка мохтаж. Араларында зур туземлелек сорап тэрбиялэргэ кирэк олкэннэр дэ бар. Шулай ук алар авыл җирлеге уздырган чараларның да актив катнашучылары. Башка бюджет өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр дә, үзләренең төп вазыйфаларыннан тыш, оештырылган чараларда актив катнашалар. Алар ярдәме белән мәдәният йорты һәм җирле үзидарә бинасы янына җиләк- җимеш агачлары утыртылды, чистарыну өмәләре, электр баганалары буяу, юл буйларын чабу, Сабантуй, Яңа ел бәйрәмнәре уздырылды. Коз коне Калморза авылы фермасында зур омэдэ катнаштылар.

Район һәм Яр Чаллы шәһәрләренә үткәрелгән ярминкәләрдә сату эшләрен оештыруда ярдәм иттеләр.

Авыл җирлегендә 3 кибет, 1 кафе эшли. Кибетнең берсе ПО "Алабуга "карамагында, югары очтагы "Ләйлә" кибете шәхси эшмәкәр Гатауллина Зиләнеке, урта очтагы "Ык дулкыннары" кибете һәм "Дом охотника" кафесы ИП Вәлиевнеке. Кибетләрдә яңа ипи, яшелчә, җиләк- җимеш, көнкүреш кирәк- яраклары сатыла, халык канәгать. Куян һәм Ахматовка авылларында кибет юк. Анда атнага бер тапкыр Минзэлэдэн автолавка килә. Шәхси эшмәкәр Зилә һәм Рифкат Гатауллиннар кирәк-яракларны алып килеп, халыкка хезмәт күрсәтәләр. Куян авылы халкы аларга бик рәхмәтле.

Бикбау авылы зиратынын коймалары алыштырылды. 27-28 сентябрь коннэрендэ барлык авыл халкы бергэлэп 500 м озынлыкта зират коймасы тоту омэсе оештырдык. Бу эштэ ярдэм иткэн барлык авылдашларга, жирлек депутатларына аера тормыйча тагын бер кат рэхмэт сузлэрен житкерэсем килэ.

Авылыбыз зиратындагы кирэк-яраклар кую очен тозелгэн йортны янартуда узеннэн зур олеш керткэн авылдашыбыз, Зэй муниципаль районы башлыгы Каримов Разиф Гали улына барлык авылдашлар исеменнэн рэхмэт житкерэм. Быел ул элеге йортнын эчке ягын ремонтлау очен дэ ярдэм курсэтэчэген белдерде.

Узара салым акчасы план буенча 120 мең акча җыелырга тиеш иде. Хөкүмәт һәрбер сумга 4 сум өстәп биргәндә безнең 480 мең сум акча булыр иде. Ләкин 60 мең сум гына җыелды. Бу акчалар безнең авыл җирлеге өчен зур проблема булган көнкүреш калдыкларын чыгаруны оештыру өчен кулланылачак. Алдагы ел планына районнан килеп көнкүреш калдыкларын җыюны керттек.

Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәмәү аркасында быелнын апрель аенда Куян авылында 3 йорт янды. Ул янган йортлар ихатасында үскән агачлар корыдылар. Газ һәм электр чыбыкларына төшеп, тагын да зуррак фажига чыгарырга мөмкиннәр. Авыл халкы һәм газ, электр хезмәтләре ярдәме белән ул агачларны кисү эшен язга кадәр тормышка ашырасы бар.

8 ноябрь тонендэ Бикбау авылында да бер хужалыкта янгын чыгып, йорт тулаем янып бетте. Авыл халкы жыелышып Нурия апа Долфенуровага акчалата ярдэм оештырдык.

Бикбау авыл җирлеге буенча 1417,5 га пай җире рәсмиләштерелеп "Мензелинские зори" агрофермасына арендага бирелде. Пай җирләре өчен август аенда халык 2 ц исәбеннән фураж алды. Җирлек буенча рәсмиләштерелгән пай җирләре 575, 141 кешенең җире рәсмиләштерелмәгән. Бикбау авыл җирлегенә кергән җирләрнең 97,21 гектары органик групп"Минзәлә"дә.

Халык соравы буенча елга берничә мәртәбә Чаллы азык-төлек продуктлары комбинаты авылда он һәм көрпә сату ярминкәләре оештыра. ХПП директоры Алмаз Хантимерович Шариповка авыл халкы исеменнән зур рәхмәт әйтәсе килә һәм тагын да мондый ярминкәләр оештырылсын иде дигән теләктә калабыз.

Җирлек буенча 272 мең сум налог җыю планда каралган иде. Үтәлеше – 306370 сум. 113% ка үтәлгән.

2015 елда "Чиста шәһәр" оешмасы Бикбау җирлегенә 183934 сумлык хезмәт күрсәтте. "Татавтодор" трасса белән беррәттән Ленин урамын да кардан чистартып тора.

Бу урында Ахматовка авылында яшәүчеләрнең дә үтенечен әйтми калып булмас. Юл чистартырга килгән транспорт Куян авылы башыннан гына борылып китә, Ахматовка авылына барып тормый. Барса да авыл башындагы беренче йорт буеннан борылып китэ. Ә бит ул авылнын икенче башында да кешеләр яши.

Бикбау авылында Татарстан республикасының "Авылның социаль йөзен үзгәртү" федераль максатчан программасы буенча су кертү эшләре башкарылды. Су кертү эшләрен "Монолит" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте башкарды. 2015 елда 1 220 000 сумлык эш башкарылды. Бүгенге көнгә Зеленая, Вахитов, Садовая, Гагарин, Комсомол урамнарына, Ленин урамынын очтэн беренэ торбалар сузылып беткән. Торба сузылган урамнарга су агуда бернинди дә токарлык юк. Бугенге көндә 130 хуҗалыкның өйләрендә су ага. Авыл халкының күптәнге хыялы тормышка ашып бара. Башняның эшләвен пенсионер Фархетдинова Розалия апа күзэтеп тора. Суга акча җыю 1 айга 1 кешегә 50 сум, 1 куб.метрга 50 сум исәбеннән оештырыла. Түләү авыл советында башкарыла.

2015 елда суга 47750 сум акча җыелган. Башняны карап торган өчен Фәрхетдинова Розалия апага 4000 сум түләнгән. Калган сумма банкка салынган. Ул акчалар башняны эшләтү өчен сарыф ителгән элетроэнергиягә түләү өчен тотыла.

2016 елда Ленин һәм Береговая урамыннарына 730 м озынлыкта торба сузасы бар. Бу урында тагын бер кечкенә генә проблема килеп туа. Авыл буенча Ленин урамына караган 6 тыкрык, Садовая урамына караган 1 тыкрыкта яшәүчеләр өчен үзәктән су кертү зур суммага төшәчәк.

Ә ул тыкрыкларда гомерләрен авыл хуҗалыгы хезмәтенә багышлаган Бөек Ватан сугышы ветераны, тыл һәм хезмәт ветераннары яши. Бу проблеманың да уңай чишелеше булыр дип ышана авылдашлар.

Узган җыенда Садовая урамында яшәүчеләр яз-көз вакытларында бу урамга транспорт белән кереп тә, йөреп тә булмаудан зарланганнар иде. Мэктэп автобусы шоферы яшэгэн элеге урам халкынын да гозере хэл ителде. Ике атна вакыт эчендэ урамга 625 м озынлыкта щебенка жэелде. Жирле бюджеттан 2 млн сум акча тотылды. Алдагы елга Гагарин урамына(750м) щебенка жэю планга кертелде.

Бу урында Куян авылы халкынын морэжэгэтен дэ житэкчелеккэ житкерэсе килэ. Бу ике авыл озак еллар дэвамында юлсызлыктан интегэлэр. Укучы балаларны йортуче автобус та кайбер коннэрне элеге авылларга керэ алмый. Сөт җыючы машина да яз-көз айларында әлеге авылларга керә алмый.

Авылның тагын бер проблемасы электр баганаларында яктырткыч лампочкалар куелмауда, урамнарның карангылыгында иде. 2014 елда 20 лампочка куелган булса, 2016 елда Бикбау авылында Ленин, Комсомол урамнарына, Куян авылынын Советская урамына, Ахматовка да Луговая урамнарына электр лампочкалары куелачак.

Бөек Ватан сугышында яу кырында ятып калган авылдашлар хормэтенэ Куян авылында тозелгэн памятник һәм Бикбаудагы "Батырлар төбәге" мемориаль комплексы бюджет хезмэткэрлэре тарафыннан чистартып, карап, буяп торыла. Яз коне комплекска утыртырга чэчэклэр алып кайтып биргэн авылдашыбыз Галиева Голсия Мулланур кызына да зур рэхмэт хислэрен житкерэсе килэ.

Авыл кулэмендэ оештырылган торле мероприятиелэрне уздыруда матди ярдэм курсэткэн «Мензелинские зори» агрофирмасы житэкчесе Габдрахманов Ростэм Хатип улына, Каримов Марат Ришат улына, Салахов Айдар Фаслах улына, Кэримов Разиф Гали

улына, Алмазия хэм Хэйдэр Мардамшиннарга, Илгизэр, Илдус, Азат Ахметхановларга, Сарваров Марсил Фатих улына, Куцаева Голжэннэт Имамагзам кызына эшләрендә уңышлар, гаилә иминлеге, ныклы сәламәтлек телибез.

**2016 нчы елга бурычлар һәм планнар.**

1. Авыл советы бинасына капиталь ремонт ясау.

2. Гагарин урамы юлына ремонт

3. Яна зират коймасын тотып бетеру.

4. Бикбау авылының Ленин, Комсомол, Куян һәм Ахматовка авылларына яңа электр үткәргечләре сузып яктырткыч лампочкалар кую.

5. Иске зират коймасының Зеленая урамы ягын яңарту.

6. Ленин урамының калган өлешенә, Береговая урамына су линияләрен сузып бетерү.

7. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү(мәчет янындагы бакчаны, иске мәктәп янындагы барлык территорияне)

8. Өч авылда да свалкаларны тәртипкә китерү.

9. Куян, Ахматовка авылларына юлларны ремонтлау.

10. Куян авылына кое казу.

**Хөрмәтле иптәшләр!** 2015 елда сезнен белән бергәләп эшләгән эшләребезнең төп моментлары шушылар иде. 2016 елда алда торган бурычларны хәл итүдә барыбыз да бергәләп эшләрбез дип ышанам.

Чыгышымны йомгаклап, барыбызга да бары тик сөенеч, шатлыклар, гаилә иминлеге, тән сәламәтлеге, җан тынычлыгы, бәхетле тигез картлык, ил- көннәребезгә иминлек, тынычлык телим.